**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

“16” ноябрь 2024 ел. №245

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлары, сайланган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы Әтнә район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы 182 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 №281, 14.06.2018 №481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 №1320, 17.11.2021 №1087, 13.12.2021 №1222, 17.09.2022 №1015, 30.04.2024 №290, 25.09.2024 №829 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Әтнә район Советы **карар кабул итте:**

1. Әтнә район Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы карарына (Әтнә район Советының 18.11.2022 №144, 27.01.2023 №167, 15.05.2024 №228 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1нче пунктта «13323» саннарын «13990» саннары белән алмаштырырга;

1.2. күрсәтелгән карарның 2 һәм 3 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымталар).

2. Әлеге үзгәрешләр 2025 елның 01 январеннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча һәм Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары-
Әтнә район Советы рәисе урынбасары Ф.М.Нуриев

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 29.03.2022 ел, №120 карарына 2 кушымта
(Татарстан Республикасы Әтнә район Советынын «16» 11 2024 ел №245 карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы, Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Коэффициент |
|---|---|
| | 8 нче группа |
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 37 036 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 33 333 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 33 333 |

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Советының 29.03.2022 ел, №120
карарына 3 кушымта
(Татарстан Республикасы Әтнә район
Советынын «16» 11 2024 ел №245
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле
үзидарә башлыкларын, депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын,
нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә даими ашыручы,
Контроль-хисап палатасы Рәисе, айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Унберенче группа | Уникенче группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 20 991 | 19 173 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 15 085 | 13 991 |
| Депутат | 13 990 | 13 990 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 13 990 | 13 990 |